КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1537

2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 ноябрь, 1537 нче
карары белән расланды

## 2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

### I. 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре

2024 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләрен раслау һәм Федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карары белән расланган Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып эшләнде.

2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) гамәлгә ашыруның төп максаты – Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең максималь эффективлыгын һәм аның табышлылыгын тәэмин итү.

Татарстан Республикасының икътисадый үсеше өстенлекләрен исәпкә алып, 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары:

житештерүнең инновацияле структураларына инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итү кысаларында 2024 елда Татарстан Республикасы милкендәге акционерлык җәмгыятьләрнең акцияләрен хосусыйлаштыру һәм дәүләт унитар предприятиеләрен хуҗалык җәмгыятьләренә үзгәртеп кору планлаштырыла.

Әлеге Фараз планына кертелгән, финанс елы тәмамлану вакытына хосусыйлаштырылмаган дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

2024 елда, бу Фараз планына кертелгән акцияләр торгларда сатылган очракта, аларны хосусыйлаштырудан Татарстан Республикасы бюджетына торглар барышында алынган суммада керемнәр керү көтелә.

## II. 2024 елда хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте

### 2024 елда акцияләре хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

| Акционерлык җәмгыятенең исеме һәм урнашу урыны | «Алтын акция» булу | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, процент | Хосусыйлаштырырга планлаштырыла торган акцияләр саны | |
|---|---|---|---|---|
| | | | данә | устав капиталы проценты |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Склад хуҗалыгы һәм ярдәмче транспорт эшчәнлеге | | | | |
| «Нижнекамскресурсы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре | юк | 11,99 | 6 368 | 11,99 |
| «Бөгелмә элеваторы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Бөгелмә шәһәре | юк | 25 процент + 1 акция | 94 473 | 25 процент + 1 акция |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре | юк | 7,69 | 2 566 | 7,69 |
| Әзер металл эшләнмәләр (машиналардан һәм җиһазлардан башка) җитештерү | | | | |
| «КАИ-Лазер» сәнәгать лазер технологияләренең төбәк инжиниринг үзәге» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 71,73 | 437 167 892 | 71,73 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек | | | | |
| «9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 45,18 | 37 090 000 | 45,18 |
| Электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итү; һава кондиционерлау | | | | |
| «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 96,6 | 606 479 | 0,92 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Су транспорты эшчәнлеге | | | | |
| «Татфлот» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 25 процент + 1 акция | 3 711 | 25 процент + 1 акция |

2024 елда хосусыйлаштырылырга тиешле
дәүләт унитар предприятиеләре исемлеге

| Дәүләт унитар предприятиесе исеме | Дәүләт унитар предприятиесенең урнашу урыны |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | |
| «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре |
| «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | |
| «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре |
| Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | |
| «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре |
| Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | |
| «Татарстан китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе | Казан шәһәре |